Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Иске Суркино авыл Советы

# КАРАРЫ

17 декабрь 2024 ел № 108

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертү, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлеге Уставының XIV бүлеге, 2024 елның 2 августындагы гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2024 елның 12 июлендәге протест, 2024 елның 27 сентябрендәге тәкъдимен карап,

Иске Суркино авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлеге Уставына (Иске Суркино авыл Советының 2012 елның 05 июлендәге 101 номерлы, 2013 елның 28 августындагы 163 номерлы, 2014 елның 19 декабрендәге 245 номерлы,2016 елның 12 маендагы 38 номерлы, 2017 елның 12 апрелендәге 61 номерлы, 2018 елның 04 июлендәге 88 номерлы , 2019 елның 14 маендагы 109 номерлы, 2020 елның 12 маендагы 128 номерлы, 2021 елның 27 сентябрендәге 28 номерлы, 2023 елның 19 маендагы 77 номерлы, 2024 елның 23 апрелендәге 94 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) кушымта нигезендә түбәндәге үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны Иске Суркино авылы, Үзәк урамы, 77 йорт, Яңа Суркино авылы, Үзәк урамы, 12а йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында игълан итәргә, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясының 8 өлешенә ярашлы рәвештә үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Иске Суркино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезләмәләре (әлеге карар редакциясендә) Иске Суркино авыл Советы депутатлар санына кагылышлы өлешендә, Иске Суркино авыл Советы депутатларын сайлауларны уздыруга бәйле рәвештә барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла, әлеге карар үз көченә кергән көннән соң.

5. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны Иске Суркино авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

Иске Суркино
авыл җирлеге башлыгы Н.В. Леонтьев

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Иске Суркино авыл Советының
2024 елның 17декабрендәге
108 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Иске Суркино авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү

1) 5 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 21 пункт өстәргә:

«21) «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру.»;

б) икенче абзацта 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирлекнең җирле үзидарә органнары Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен, Татарстан Республикасы вәкаләтләрен тиешле вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү максатларында җирле бюджетка бирелгән субвенцияләр чикләрендә гамәлгә ашыру өчен җаваплы.»;

2) 7 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирлектә муниципальара хезмәттәшлек федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

3) 10 статьяның 7 өлешендәге икенче абзацында «җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе (алга таба – сайлау комиссиясе)» сүзләрен «тиешле референдум комиссиясе» сүзләренә, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы» сүзләрен «Татарстан Республикасы башкарма органы» сүзләренә алмаштырырга;

4) 11 статьяның 4 өлешендәге икенче абзацында «сайлау комиссиясе» сүзләрен «тиешле сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

5) 21.1 статьяның 5 өлешендәге икенче абзацында «1-7 пунктларында» сүзләрен «1-7 һәм 9.2 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга;

6) 24 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирлек Советы бермандатлы сайлау округлары буенча муниципаль сайлауларда сайлана торган 7 депутаттан тора.

2. Составына җирлек Советының билгеләнгән саныннан өчтән икедән ким булмаган депутат сайланганда җирлек Советы тулы хокуклы була. (ягъни биш депутаттан да ким булмаган).»;

7) 25 статьяда:

а) 1 өлешнең икенче җөмләсен төшереп калдырырга;

б) 2 өлешнең 2 пунктындагы б пунктчасында «(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе)» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 8 өлештә «(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе)» сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 9 өлештә «(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе)» сүзләрен төшереп калдырырга;

7) 28 статьяның 1 өлешендәге 25.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«25.2) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау;»

8) 35 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 11.1 пунктча өстәргә:

«11.1) аның чит ил агенты статусын алуы;»;

б) 2 өлешнең икенче абзацында «(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе)» сүзләрен төшереп калдырырга;

9) 41 статьяның 4 өлешендә «(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе)» сүзләрен төшереп калдырырга;

10) 43 статьяның 1 өлешендә «җирлек башлыгы» сүзләрен "Башкарма комитет җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга»;

11) 44 статьяның 1 өлешендә:

а) 5 пунктка түбәндәге эчтәлекле өченче абзац өстәргә:

«-шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә ала.»;

б) 7 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыра, аның предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү тора, күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыра;»;

12) 55 статьяның икенче абзацында «(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе)» сүзләрен төшереп калдырырга;

13) 57 статьяда:

а) 1 өлештә «(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе)» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 4.1 пунктча өстәргә:

«4.1) аның чит ил агенты статусын алуы;»;

в) 3 өлештә «(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе)» сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 4 өлештә «(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе)» сүзләрен төшереп калдырырга;

д) 5 өлештә «(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе)» сүзләрен төшереп калдырырга;

е) 6 өлештә «(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе)» сүзләрен төшереп калдырырга;

ж) 7 өлештә «(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе)» сүзләрен төшереп калдырырга;

з) 11 өлешнең 1 пунктчасында «(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органы җитәкчесе)» сүзләрен төшереп калдырырга;

и) 14 өлештә «(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе)» сүзләрен төшереп калдырырга;

14) 67 статьяда:

а) 1 өлешнең 17 пунктчасын төшереп калдырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 5 өлеш өстәргә:

«5. Җирле үзидарә органнары Россия Федерациясенең электр энергетикасы турындагы законнарында билгеләнгән очракларда, тәртиптә һәм шартларда муниципаль милектәге, система барлыкка китерүче территориаль челтәр оешмасының яисә Татарстан Республикасы чикләрендә эш итүче территориаль челтәр оешмасының электр челтәре хуҗалыгы объектларын түләүсез биләүгә һәм файдалануга тапшыруны гамәлгә ашыралар.».

Иске Суркино
авыл җирлеге Башлыгы

Н.В. Леонтьев